**Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы**

БОЕРЫК

07.07.2015 ел Казан ш. № 11-65

30.10.2013ел, №11-112 Татарстан
Республикасы Финанс министрылгы
боерыгына үзгәрешләр кертү

“Коррупциягә каршы эшчәнлек мәсьәләләре буенча Россия Федерациясенең аерым законнар актларына үзгәрешләр кертү турында” 22 декабрь, 2014 ел, № 431-ФЗ Федераль закон, “Коррупциягә каршы эшчәнлек мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы Президентының аерым указларына үзгәрешләр кертү турында” 23 март, 2015 ел, № УП-308 Татарстан Республикасы Президенты Указы нигезендә, боерык бирәм:

1. “Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы аппаратында һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаментында Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында” 30.10.2013 ел, № 11-112 Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы боерыгына (Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 11.03.2014 ел, № 21-11-150л боерыгы нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбуласын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Керемнәр, чыгымнар, милек һәм мөлкәт характерындагы бурычлар турында белешмә формасын раслау һәм Россия Федерациясе Президентының аерым актларына үзгәрешләр кертү турында” 23.06.2014 ел, № 460 Россия Федерациясе Президенты Указын һәм “Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәткәрләре үзләренең вазыйфасын биләгәндә керемнәре, милке һәм мөлкәт характерындагы бурычлары, шулай ук иренең (хатыны) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, милке һәм мөлкәт характерындагы бурычлары турында мәгълүматлар тапшыруны таләп итүче Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында” 30.12.2009 ел, № УП-701 Татарстан Республикасы Президенты Указын үтәү йөзеннән”;

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“1. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы аппаратында һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаментында Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәткәрләре үзләренең вазыйфасын биләгәндә керемнәре, чыгымнары, милке һәм мөлкәт характерындагы бурычлары, шулай ук иренең (хатыны) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, милке һәм мөлкәт характерындагы бурычлары турында мәгълүматлар тапшыруны таләп итүче Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәте вазыйфалары исемлеген (алга таба – Исемлек) (кушымта итеп бирелә) расларга.”;

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“2. Исемлеккә кертелгән вазыйфаларны биләгән затларга дәүләти гражданлык хезмәтеннән киткәндә “Коррупциягә каршы эшчәнлек турында”

25.12.2208 ел, № 273-ФЗ Федераль законның 12 статьясында күздә тотылган чикләүләрне, бурычларны һәм җаваплылыкны аңлатырга.”;

әлеге боерык белән расланган Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы аппаратында һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаментында дәүләти гражданлык хезмәтенә дәгъва кылучы гражданнар үзләренең керемнәре, милке һәм мөлкәт характерындагы бурычлары, шулай ук иренең (хатыны) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, милке һәм мөлкәт характерындагы бурычлары турында, шулай ук Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы аппаратында һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаментында Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәткәрләре үзләренең вазыйфасын биләгәндә керемнәре, чыгымнары, милке һәм мөлкәт характерындагы бурычлары, шулай ук иренең (хатыны) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, милке һәм мөлкәт характерындагы бурычлары турында мәгълүматлар тапшыруны таләп итүче Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәте вазыйфалары исемлеге атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы аппаратында һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаментында Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәткәрләре үзләренең вазыйфасын биләгәндә керемнәре, чыгымнары, милке һәм мөлкәт характерындагы бурычлары, шулай ук иренең (хатыны) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, милке һәм мөлкәт характерындагы бурычлары турында мәгълүматлар тапшыруны таләп итүче

Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәте вазыйфалары исемлеге”.

2. Кадрлар бүлеге начальнигы Г.Х.Мәкъсудовага бу боерыкны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына дәүләт теркәвенә алуга тапшырырга.

**Министр** **Р.Р.Гайзатулин**